РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава Тумутукского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана, д.62 Б, Азнакаевский район,
с.Тумутук, 423316,
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
башлыгы

Тельман ур., 62 Б йорт, Азнакай районы,
Тымытык авылы, 423316
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«22»сентябрь 2023 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставының 15.1 маддәсе нигезендә, Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**карар итте:**

1. 2023 елның 9 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Кук-Тәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы - барча йортлар, Җәлил урамы - барча йортлар, Яшьләр урамы - барча йортлар.

2. 2023 елның 9 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Кук-Тәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә: Ленин урамы - барча йортлар.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Кук-Тәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты –9 октябрь 2023 ел 10.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
   - гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты –9 октябрь 2023 ел 14.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Күк-Тәкә авылы, Ленина ур. , 40 йорт, күпфункцияле үзәк залы;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт;

-сайлау хокукына ия булган Күк-Тәкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Күк-Тәкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Күк-Тәкә авылында Өске зиратны коймалау өчен материаллар сатып алу (материал сатып алу һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү);

- Күк-Тәкә авылында Ленин, Җәлил, Совет урамнарында вак таш җәелгән юлны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» "КАРШЫ"

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман ур., 62Б йорт, Күк-Тәкә авылы, Ленина ур., 40 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы Э.Х.Гыйләҗева